**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**06.09.2019** **№ 1513**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алуны оештыру турында

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”, 2019 елның 19 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгәннәрне расларга:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алу турында Нигезләмәне (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алу буенча комиссия составын (2 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алу буенча документларны (3 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасын гамәлгә кертү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча техник биремне (4 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Хәкимуллин Р.Ф.га йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

РАСЛАНГАН
Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
06.09.2019 № 1513

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алу турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторын сайлап алу турында Нигезләмә (алга таба – сайлап алу) сайлап алуны оештыруны, аны үткәрү тәртибен, катнашу шартларын, тәкъдимнәрне карау тәртибен, шулай ук кабул ителгән карарны раслау һәм юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасын кертү һәм аларга хезмәт күрсәтү хокукын рәсмиләштерү процедурасын регламентлый.

1.2. Нигезләмә Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”, 2019 елның 19 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә эшләнде.

1.3. Сайлап алуда вәкаләтле зат булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

1.4. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге сайлап алуны оештыручы буларак чыгыш ясый. .

## 2. Сайлап алуның максаты

Сайлап алу халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын күтәрү, билетсыз йөрү һәм юл йөрү документларын ялган итеп ясау, ташламалы йөрүнең төгәл санын теркәү өчен үткәрелә.

## 3. Сайлап алуларда катнашуның шартлары

3.1. Сайлап алуда оештыру-хокукый формасына, милек формасына, урнашу урынына (алга таба – Дәгъвачылар) бәйсез рәвештә, түбәндәге таләпләргә туры килә торган юридик затларга катнашу мөмкинлеге бирелә, төгәлрәк әйтсәк:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә товарлар җибәрүне, эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы, сайлап алу предметы булып торган затларга карата билгеләнә торган таләпләргә Дәгъвачыларның туры килүе турында таләпләр;

- Дәгъвачыны – юридик затны юкка чыгармау таләбе һәм сайлап алуда катнашучыны – юридик затны банкрот дип тану турында арбитраж суды тарафыннан кабул ителгән карарның булмавы һәм сайлап алу эшен ачу турында;

- сайлап алуда катнашу өчен гариза биргән көнгә Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә Дәгъвачының эшчәнлеген туктатып тормау турында таләп;

- Дәгъвачының теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына күләме соңгы тәмамланган хисап чорында бухгалтер хисабы мәгълүматлары буенча сайлап алуда Катнашучы активларының баланс бәясенең егерме биш процентыннан артык булган исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау таләбе. Сайлап алуда Катнашучы, әгәр ул Россия Федерациясе законнары нигезендә, күрсәтелгән бурычның булу-булмавына шикаять бирсә һәм сайлап алуда катнашу өчен гаризаны карау көненә шундый шикаять буенча карар кабул ителмәсә, билгеләнгән таләпкә туры килә дип санала.

3.2. Сайлап алуда катнашырга Дәгъвачы тарафыннан тәкъдим ителә:

- сайлап алуда катнашу өчен гариза;

- юридик затлар өчен – юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, сайлап алуны үткәрү турында рәсми сайтта урнаштырганчыга кадәр алты айдан да иртәрәк вакытта алынмаган алынган юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки мондый күчермәнең нотариаль расланган күчермәсе;

- чит ил юридик затлары өчен – дәүләт законнары нигезендә юридик затларны дәүләт теркәвенә алу турындагы тиешле рәвештә рус теленә тәрҗемә ителгән, ачык сайлап алу үткәрү турында хәбәрнең рәсми сайтта урнаштыру көненә кадәр алты айдан да иртәрәк вакытта алынмаган документлар;

- Дәгъвачы-юридик зат исеменнән эш-гамәлләр башкаруга затның вәкаләтен раслаучы документ (билгеләү турында яки сайлау турында карар күчермәсе, яки физик затның ышаныч кәгазеннән башка гына Дәгъвачы исеменнән эш итү хокукы булган физик затны билгеләү турында боерык (алга таба җитәкче). Әгәр дә Дәгъвачы исеменнән башка зат гамәлдә булса, сайлап алуда катнашуга гаризада Дәгъвачының мөһере белән таныкланган һәм Дәгъвачының җитәкчесе (юридик затлар өчен) яисә әлеге җитәкче тарафыннан вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган гамәлләрне тормышка ашыруга Дәгъвачы исеменнән ышаныч кәгазе яки мондый ышаныч кәгазенең нотариаль расланган күчермәсе булырга тиеш. Әгшр дә күрсәтелгән ышаныч кәгазе Дәгъвачының вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, сайлап алуда катнашуга гаризада шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслаучы документ булырга тиеш.

- Дәгъвачының оештыру документлары күчермәләре (юридик затлар өчен); -
- проектны үтәү шартлары турында тәкъдимнәр.

3.3. Тапшырыла торган документлар, аларның формасы һәм сайлап алуны уздыру сроклары турында тулырак мәгълүмат Вәкаләтле зат тарафыннан һәр сайлап алу алдыннан раслана торган документларда күрсәтелә.

Дәгъвачылар бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплылык йөртә.

## 4. Сайлап алуны уздыру вакыты һәм тәртибе

4.1. Вәкаләтле зат сайлап алуда катнашу өчен гаризалар салынган барлык конвертларны ачып җибәрә һәм сайлап алуда катнашу өчен электрон документлар формасында бирелгән гаризаларга керү мөмкинлеген ача. Беренче конверт ачылганчы Комиссия катнашучы Дәгъвачыларга, гариза салынган конвертларны һәм сайлап алуда катнашу өчен электрон документлар формасында бирелгән гаризаларга керү мөмкинлеген ачканчы, гаризалар бирү, үзгәртү яки кире алу мөмкинлеге турында игълан итә.

4.3. Гаризалар салынган барлык конвертлар да чират буенча ачыла. Гаризалар салынган конвертларны ачканда түбәндәге мәгълүматлар укыла: Дәгъвачының исеме (юридик зат өчен), почта адресы, документларда каралган мәгълүматларның һәм документларның булуы, гаризада күрсәтелгән һәм сайлап алуда катнашуга гаризаларны бәяләү критерие булган килешүне үтәү шартлары. Барлык мәгълүматлар конвертларны ачу беркетмәсенә кертелә.

4.4. Сайлап алуда катнашуга гариза биргән Дәгъвачылар яки аларның вәкилләре сайлап алуда катнашуга гаризалар салынган конвертларны ачкан вакытта катнашырга хокуклы. Дәгъвачылар вәкилләре дәгъвачы исеменнән эш-гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслаучы документ тапшыралар. Оешманың беренче затлары булмаган Дәгъвачылар вәкилләре булган очракта, сайлап алуда Катнашучының мәнфәгатьләрен яклауга ышаныч кәгазе тапшырылырга тиеш.

4.5. Конвертларны ачканда катнашучыларның һәм затларның барысы да дәгъвачылар вәкилләрен Комиссия сәркатибе тарафыннан төзелә һәм имзалана торган Дәгъвачыларның вәкилләрен теркәү кәгазендә теркәләләр.

4.6. Конвертларны ачу беркетмәсе Комиссия тарафыннан алып барыла һәм гариза салынган конвертларны ачканнан һәм сайлап алуда катнашу өчен электрон документлар формасында бирелгән гаризаларга керү мөмкинлеген ачканнан соң ук барлык Комиссия әъзалары һәм Вәкаләтле орган тарафыннан имзалана. Әлеге беркетмә Вәкаләтле орган тарафыннан беркетмәгә кул куелган көннән соң килә торган көн дәвамында рәсми сайтта урнаштырыла.

4.7. Вәкаләтле орган конвертлар ачуның аудиоязмасын гамәлгә ашыра. Конвертларны ачканда катнашучы һәр Дәгъвачы мондый конвертларны ачуның аудио-һәм видеоязмасын тормышка ашырырга хокуклы. Шул ук вакытта мондый Дәгъвачы конвертларны ачу процедурасына кадәр комиссиягә аудио - яки видеоязманы тормышка ашыру нияте турында хәбәр итәргә тиеш.

Сайлап алуда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң, сайлап алуда катнашу өчен бер генә гариза бирелгән яисә сайлап алуда катнашуга бер генә гариза да бирелмәгән булса, сайлап алу узмаган дип таныла.

## 5. Сайлап алуда катнашуга тапшырылган гаризаларны бәяләү критерийлары

5.1. Комиссия сайлап алуда катнашу өчен Дәгъвачы тарафыннан бирелгән гаризаларны бәяләүне һәм документларда язылган бәяләү критерияләренә туры килүне чагыштыруны гамәлгә ашыра.

5.2. Комиссия сайлап алу предметы буенча иң яхшы шартлар тәкъдим иткән, лот буенча сайлап алу гаризаларын бәяләү нигезендә беренче номер бирелгән Дәгъвачыны җиңүче дип таный.

## 6. Сайлап алуны уздыруны әзерләү һәм үткәрүне

6.1. Сайлап алуның Вәкаләтле заты конкурсны оештыручыны билгели.

6.2. Конкурсны оештыручы:

6.2.1. сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмати хәбәр урнаштыруны оештыра һәм документлар таратуны гамәлгә ашыра;

6.2.2. Дәгъвачыларны әлеге Нигезләмә белән таныштыра һәм аларга сайлап алуны оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча бушлай консультация хезмәтләре күрсәтә;

6.2.3. Дәгъвачыларның Комиссиягә тапшыру өчен кирәкле документларын кабул итә һәм терки, кирәк булганда Дәгъвачы тәкъдим иткән мәгълүматның дөреслеген тикшерә;

6.2.4. документларда расланган график нигезендә сайлап алуны үткәрә һәм Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

6.2.5. Интернет челтәрендә сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра.

## 7. Ачык сайлап алуда җиңүче, ачык сайлап алуда катнашучы, ачык сайлап алуда катнашуга гариза биргән бердәнбер Дәгъваы, ачык сайлап алуда бердәнбер катнашучы дип танылган бердәнбер Дәгъвачы килешү проектын имзаларга тиешле срок

7.1. Ачык сайлап алуда җиңүче яисә ачык сайлап алуда бердәнбер катнашучы Дәгъвачының килешүгә кул кую вакыты: бәяләү һәм сайлап алуда катнашу өчен гаризаларны чагыштыру беркетмәсен сайтта урнаштырылганнан соң кимендә 10 (ун) көн һәм ачык сайлаулар үткәрелгәннән соң 12 (унике) көннән дә соң булмаган срокта.

7.2. Ачык сайлап алуда катнашуга гариза биргән бердәнбер катнашучы яки сайлап алуда катнашучының бердәнбер катнашучысы дип танылган килешүгә кул кую вакыты рәсми сайтта ачык сайлап алуда катнашу өчен

гаризаларны карау беркетмәсе урнаштырылганнан соң 10 (ун) көннән дә ким түгел һәм сайлап алуда катнашу өчен гаризалар каралганнан соң 12 (унике) көннән дә артмый.

3 нче кушымта

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
06.09.2019 № 1513

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль җәмәгать транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасын гамәлгә кертү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча
ТЕХНИК БИРЕМ

Биектау ст.

2019 ел

1. Гомуми мәгълүматлар

1.1. АСОПны кертүнең чик сроклары:
2019 елның 10 декабренә кадәр

1.2. Хезмәт күрсәтү урыны:
Татарстан Республикасы

1.3. АСОПка хезмәт күрсәтүгә таләпләр: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында АСОПка хезмәт күрсәтү өчен шартлар, җиһазлар, хезмәткәрләрнең булуы.

2. Терминнар һәм кыскартулар

АСОП – Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр пассажир транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы;
ЦОД - мәгълүматларны эшкәртү үзәге;
ПБ - юл билеты;
ПТК - кондукторның күчмә терминалы;
НСИ - норматив-белешмә мәгълүмат;
БСК- контактсыз смарт-карта;
АРМ - автоматлаштырылган эш урыны;
АРМ-К- кассирның автоматлаштырылган эш урыны;
АРМ ИРС - Пассажирлар белән эшләү буенча инспекторның автоматлаштырылган эш урыны;
ПУ НСИ - НСИ белән идарә итү программасы (шул ук, АРМ-Т);
УППД-юл йөрү документларын тикшерү җайланмасы;
ПТ-стационар түләү терминалы;
МТ-мобиль түләү терминалы;
АППБ - юл билетларын сату һәм тулыландыру буенча автомат
ПБ Сату җайланмасы - кассир АРМы, яки АППБ, яки стационар түләү терминалы, яки мобиль түләү терминалы;
ТС - транспорт чарасы;
ТМЦ -товар-матди кыйммәтләр;
ДС - акча;
ПО - Программалар белән тәэмин итү;
ППЗВК - гаризалар кабул итү һәм карталар бирү пунктлары;
ППК-карталар тулыландыру пунктлары;
УЧЗ - БСК язмаларын язу һәм уку җайланмасы;
БД - мәгълүматлар базасы;
ПФО - хисапларны формалаштыру подсистемасы;
"Кара исемлек» - куллану тыелган билетларның исемлеге;
“Соры исемлек " - куллануның хокуклылыгына өстәмә тикшерү таләп итә торган юл йөрү билетлары исемлеге.

3. АСОП таләпләре, аның техник характеристикалары

3.1. АСОПны кертүгә таләпләр

1. Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында АСОПны кертү.

АСОПны гамәлгә кертү өчен түбәндәге эшләрне башкарырга кирәк:

1. Казан шәһәрендә түбәндәге параметрлар белән бердәм ЦОД оештыру:

- АСОП мәгълүматларын эшкәртү өчен тәүлегенә кимендә 2 млн. транзакция күләмендә 200 тәрдән дә ким булмаган ПБ системасы кулланыла торган исәпләү куәтләре.

- АСОП мәгълүматларын ышанычлы саклау өчен җитәрлек мәгълүмат саклау системасы;

- ЦОДны ышанычлы электр белән тәэмин итә торган өзлексез туклануны тәэмин итү (2 бәйсез электр туклану чыганагы булу мәҗбүри, шәһәр челтәрләреннән бәйсез туклану чыганагы (дизель/газ генераторы) булуы мәслихәт);

- кондиционерланган бина, кондиционер системасы куәте ЦОД тагы температураны ел әйләнәсенә 18-25 градус диапазонда тәэмин итәргә тиеш;

- ЦОДның физик яктан сакланулы булуы, ул:

- ЦОД биналарына керү белән идарә итү һәм контроль системасы;

- янгын сүндерү газ системасы;

- саклау күләме 90 көннән дә ким булмаган видеокүзәтү системасы;

- 24/7/365 саклау режимы тәэмин ителергә тиеш;

- "кайнар" резерв режимында эшләүче 2 бәйсез элемтә каналлары булу;

2. Эшкә сәләтле контактсыз смарт-карталар (БСК) әзерләү һәм бирү. Чыгарылган карталарның кирәкле саны:

- 2019 елның 10 декабренә кадәр ташламалы категория гражданнары өчен 10000гә кадәр шәхсиләштерелгән БСК (өстәмә чыгару килешү буенча);

- 2019 елның 10 декабренә кадәр гражданнарның ташламалы категорияләренә шәхсиләштерү өчен 10000 БСК әзерләү;

- 2019 елның 10 декабренә кадәр 200 түләүле БСК (өстәмә чыгару килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль берәмлекнең транспорт предприятиеләре белән шартнамәләр төзү.

4. Шәһәр җәмәгать транспорты һәм шәһәр яны автомобиль транспорты транспорт предприятиеләрен БСК нигезендә электрон юл йөрү билетларына автоматлаштырылган контроль чаралары белән тәэмин итү һәм аларның контроле астында алынган мәгълүматны беренчел эшкәртү:

5. Гаризалар кабул итү һәм ташламалы электрон транспорт карталары бирү пунктлары челтәрен оештыру.

6. Электрон юл йөрү билетларын сату һәм тулыландыру челтәрен булдыру.

7. Бу система Татарстан Республикасының барлык территориясендә кертелергә тиеш, шулай итеп, Татарстан Республикасына кертелә торган

система Казан, Әлмәт, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә Башкарма комитет акчалары яки аларга җәлеп ителгән акчалар хисабына кертелә торган АСОП системасына интеграцияләнү мөмкинлеге булдырырга тиеш, шул исәптән АСОП программа тәэмин ителешен эшләп бетерү бәясен дә кертеп.

АСОПны гамәлгә кертү критерие булып тора

- таләп ителә торган параметрлар нигезендә ЦОД оештыру;

- льготалы йөрү хокукына ия булган категория гражданнарны 20% тан да ким булмаган льготалы БСК белән тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында транспорт предприятиеләре белән килешүләр төзү;

- БСК нигезендә электрон юл йөрү билетларын автоматлаштырылган контрольдә тоту чаралары белән җәмәгать транспортының 40% тан да ким булмаган җиһазландыру;

- шәһәр җәмәгать транспорты һәм шәһәр яны автомобиль транспорты предприятиеләрен 40% тан да ким булмаган күләмдә мәгълүматны беренчел эшкәртү чаралары белән җиһазлау

- 10000 ташламалы заттан да ким булмаган карталар белән тәэмин итү өчен җитәрлек күләмдә гаризалар кабул итү һәм ташламалы электрон юл йөрү билетлары бирү пунктлары челтәрен оештыру;

- 1 пункттан да ким булмаган санда электрон юл йөрү билетларын бирү, сату һәм тулыландыру челтәрен оештыру;

- 2019 елның 10 декабренә кадәр кертелә торган системаны Казан, Әлмәт, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендәге АСОП РТ белән интеграцияләү.

Гамәлгә кертүнең иң чик вакыты - 2019 елның 10 декабренә кадәр.

3.2. Системаны үстерүгә таләпләр.

Система, аппарат-программа мохите һәм эш станцияләре кысаларында кулланучылар саны артканда, эшкә сәләтлелекне сакларга тиеш.

Яңа кулланучылар җиһазларын гамәлгә кертелә торган Татарстан Республикасында АСОП системасына интеграцияләү яңа кулланучылар хисабына башкарыла.

Система модульлек һәм масштаблылык үзлегенә, аны этаплап кертү, аның функциональ мөмкинлекләрен киңәйтү мөмкинлегенә ия булырга тиеш.

3.3. Системаны билгеләүгә карата куела торган таләпләр.

Шәһәр пассажир транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы түбәндәге төп функцияләрне автоматлаштыру өчен билгеләнергә тиеш:

• кондуктор системасыннан файдаланып, БСК ярдәмендә пассажирлар тарафыннан юлда йөрү өчен түләү;

• барлык категория гражданнарның юл йөрү чыгымнарын контрольдә тоту;

• ташламаларга хокукы булган пассажирлар өчен транспортта ташламалы йөрү хокукын контрольдә тоту

АСОП системасында гамәлгә ашырылган әлеге функцияләрне автоматлаштыру түбәндәге мөмкинлекләрне алуны тәэмин итәргә тиеш:

• юл йөрү өчен түләүнең нәтиҗәле контролен арттыру;

• пассажирларга хезмәт күрсәтү культурасын арттыру;

• хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт шартларын яхшырту;

• ташламалар бирүнең шәхси исәбен тәэмин итү;

• икътисадый күрсәткечләрне яхшырту, шул исәптән пассажирлар ташудан керемнәр җыюны арттыру;

• үзәкләштерелгән идарә ителә торган тарифларның сыгылмалы системасын алып бару мөмкинлеге;

• ялган юл билетларын куллануны яки ташламалы билетлардан хокуксыз файдалануны булдырмау мөмкинлеге;

• мобиль элемтә операторы счетыннан ПБ тулыландыру өчен NFC технологияләрен куллану мөмкинлеген тормышка ашыру.

Система статистик мәгълүмат алу һәм эшкәртү мөмкинлеген бирергә тиеш:

• транспорт чараларының пассажирлар агымына, хәрәкәтенә һәм йөкләнешенә мониторинг ясау мөмкинлеге;

• төрле транспорт билетлары буенча пассажирлар ташудан керемнәрнең мониторингын үткәрү мөмкинлеге;

• АСОП эшен оптимизацияләү өчен финанс һәм статистика исәбен автоматлаштыру һәм мәгълүматларны алу

3.4. АСОП юл йөрү билетларына (ПБ) карата куела торган таләпләр.

3.4.1. ПБ төрләре.

АСОПта йөрү билетының нигезе буларак ISO 14443A Mifare® стандарты картасы кулланылырга тиеш.

Карта түбәндәге вариантларда кулланылырга мөмкин.

Тулыландырыла торган карта, ул, ташламалы яки хезмәт урыныннан кулланыла торган картадан тыш, теләсә кайсы төрдә гадәти йөрү билетын яздыру өчен каралган. Әлеге БСК ПБ сату челтәре аша сатып алына. Картаны система операторы чыгара.

Ташламалы пассажирлар өчен яки хезмәт урыныннан файдалану өчен тулыландырыла торган шәхсиләштергән карта. Әлеге карталарны система операторы вәкаләтле оешманың заявкасы буенча әзерли, шул ук вакытта аларга пассажирның шәхси мәгълүматлары һәм ПБның тиешле ташламалы яки хезмәт урыныннан икәнлеге күрсәтелә.

Берләштерелгән банк-транспорт карталары, система операторының нинди дә булса банк белән берлектә чыгарылган. Әлеге карталар транспорт БСК, һәм шулай ук социаль, банк картасы буларак та файдаланылырга мөмкин.

Пассажирлар гадәти яки ташламалы йөрү билетын алганда, сатып алганда яки тулыландырганда картага билет төрен, аның характеристикаларын бирә торган һәм аны транспортта йөрү өчен кулланырга мөмкинлек бирә торган билгеле бер мәгълүматлар язылырга тиеш.

БСКда язылган ПБ характеристикалары шулай ук АСОП мәгълүматлары базасында сакланырга тиеш, бу исә ПБ операцияләрендә хаталарны тулысынча диярлек булдырмаска, шулай ук ялган ПБ ясау яисә ташламалы ПБлардан законсыз файдалануга юл куймаска мөмкинлек бирә

3.4.2. Билет төрләре

Системада 100 төрдән дә ким булмаган юл йөрү билетларын куллану каралырга тиеш, аларны көйләү нәтиҗәсендә тариф планнарының сыгылмалы һәм уңайлы системасы тормышка ашырылырга мөмкин. Шартлы рәвештә ПБ төрләре биш класска бүленергә мөмкин:

- билгеләнгән гамәлдә булу срогы булган, йөрү саны чикләнмәгән билетлар;
- билгеләнгән гамәлдә булу срогы булмаган, йөрү саны чикләнмәгән билетлар;
- билгеләнгән гамәлдә булу срогы булган, йөрү саны чикләнгән билетлар;
- гамәлдә булу срогы чикләнгән, йөрү саны билгеле булган билетлар;
- тариф берәмлекләренең билгеле бер санына билетлар.

Һәр төр ПБ түбәндәге параметрларга туры килергә тиеш:

- ПБ төре исеме;
- ПБ классы төре (гамәлдә булу вакытына, йөрү санына яки тариф берәмлекләре санына билет);
- тарифлар таблицасы;
- көннәре гамәлдә булган ПБ (эш көннәре, ял көннәре, яисә барлык көннәрдә дә);
- гамәлдәге вакыты (бары тик "пик сәгатьләре"ндә яки теләсә кайсы вакытта).

Пассажир тарафыннан алына торган конкрет билетка языла торган мәгълүмат билгеләнгән үрнәккә туры килергә, шулай ук түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

- ПБ төренең коды;
- ПБ куллану территориясе коды;
- юл билетын сатучы сату җайланманың коды, терминалның серия номеры;
- билет номеры;
- сату датасы һәм вакыты;
- соңгы сәфәр датасы һәм вакыты һәм маршрут коды;
- йөрү билетының гамәлдә булу вакыты;
- файдаланылмаган сәфәр яки тариф берәмлекләре саны.

Ташламалы йөрү хокукына ия булган пассажирлар өчен БСК нигезендә, БСКга ташламалы пассажирның фоторәсемен һәм аның шәхси мәгълүматларының төшереп, махсус персональ ПБ билгеләнергә тиеш.

3.4.3. БСК нигезендә ПБ әйләнешкә кертү.

3.4.3.1. Юл йөрү билетларын сату һәм тулыландыру.

Системада берничә төрле сату һәм юл билетларын тулыландыру ысулы булдырылырга тиеш, бу пассажирларга уңайлы, тиз һәм вакытында юл йөрү өчен түләү мөмкинлеге бирә.

Турыдан-туры ПБ сату өчен сату пунктлары челтәрен булдыру, яки гамәлдәге челтәрне (почта бүлекләре, банклар, кәрәзле оператор салоннары һ. б.) куллану каралырга тиеш. ПБны сату һәм тулыландыру өчен билгеләнгән техник чаралар әлеге операцияләрне кассир катнашында (кассир АРМы, мобиль түләү терминалы), яисә аннан башка да (юл йөрү билетларын сату буенча автомат, стационар түләү терминалы) башкару мөмкинлеген булдырырга тиеш.

3.4.3.2. Шәхсиләштерелгән ташламалы ПБ чыгару.

БСК нигезендә шәхсиләштерелгән ташламалы ПБларны чыгару АСОПның турыдан-туры операторы тарафыннан, АСОП эшчәнлеге процессында билгеләнә торган заказчы гаризасы буенча башкарылырга тиеш. Шул ук вакытта БСКда пассажирның фотосурәте һәм аның шәхси мәгълүматлары бастырылырга тиеш.

Транспорт кушымтасы булган банк карталары тиешле банк тарафыннан чыгарылырга тиеш. Банк тарафыннан әзерләнгән карта турында мәгълүматлар АСОП процессингы белән эшкәртелергә тиеш һәм системаның мәгълүматлар базасына кертелә.

3.5. АСОП катнашучыларына карата таләпләр.

3.5.1. Система операторы (АСОП).

Башкаручы АСОП Операторын булдыра, ул система эшен оештыра, координацияли һәм контрольдә тота, системада катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге, исәп-хисаплары һәм мәгълүмат белән тәэмин итү өчен җавап бирә, аның үсешен тормышка ашыра.

АСОП операторы ЦОДны, үзенә тапшырылган җиһазларны, программа тәэминатын (ПО) һәм элемтә чараларын эш халәтендә тотарга, системаның башка катнашучыларына системага өзлексез керү һәм үзара элемтә тәэмин итәргә, шулай ук системаны эксплуатацияләү барышында килеп туган мәсьәләләрне хәл итү белән шөгыльләнергә тиеш.

Система операторының төп функцияләре:

1. Система белән гомуми идарә итү:

• АСОПның норматив-белешмә мәгълүматы (НСИ) белән идарә итү;

• системага карата таләпләр нигезендә ЦОД эшен оештыру һәм тәэмин итү;

• пассажир транспортына шәхсиләштерелгән һәм шәхсиләштерелмәгән өчен БСК эмиссиясе;

• АСОПта товар-матди кыйммәтләрнең (ТМЦ) һәм акча чараларының (ДС) хәрәкәтен исәпкә алу;

• АСОП катнашучылары сораулары буенча һәм регламент нигезендә финанс һәм статистик хисапларны формалаштыру;

• транспорт операторлары белән үзара исәп-хисап ясау;

• система эшчәнлеген анализлау.

2. Пассажирлар белән эшләү:

• Шәхсиләштерелгән һәм хезмәт БСКларын чыгару;

• ПБ сатуда һәм контрольдә тотканда барлыкка килә торган штаттан тыш хәлләр буенча пассажирлар белән эшләү.

3. Системага техник хезмәт күрсәтү

• АСОП җиһазларының торышын мониторинглау һәм анализлау;

• регламент нигезендә АСОП ЦОДына хезмәт күрсәтү һәм системалы администрацияләү;

• ПБ сату һәм тулыландыру пунктларына технологик ярдәм күрсәтү;

• системаның техник чараларына хезмәт күрсәтү.

4. БСКда ПБ сатуны оештыру

• ПБ сату пунктларының агентлар челтәрен булдыру;

• ПБ сату пунктларын оештыру;

• АРМ Кга БСК нигезендә башка сатулар белән беррәттән ПБ сатучы оешмалар-агентлар белән килешүләр төзү;

• кәрәзле элемтә операторы счетыннан ПБ тулыландыру өчен NFC технологияләрен куллану.

Югарыда тасвирланган даими функцияләрдән тыш, кирәк булганда, түбәндәге функцияләр дә үтәлергә мөмкин:

• АСОПны оештыру карарлары нигезендә транспорт предприятиеләренең эксплуатацион персоналы эшен оештыру;

• система персоналын укытуны оештыру;

• чиктәш системалар белән хезмәттәшлек;

• системаның эксплуатация һәм норматив-техник документларын алып бару;

Система операторының башка оешма-катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге алга таба алар башкара торган функцияләр турында мәгълүматларны үз эченә алган бүлекләрдә тасвирланган.

5. БСК эмиссиясен тормышка ашыру.

Система операторы БСКны эшкә әзерләргә - эмиссия үткәрергә тиеш, аның барышында юл билеты картасына алга таба кодлаштыру мөмкинлеге бирә торган керү ачкычлары язылырга тиеш. Шәхсиләштерелгән БСК чыгару. БСК нигезендә ПБ чыгаруга чыгымнар оператор акчаларыннан башкарыла.

БСК нигезендә шәхсиләштерелгән ПБлар ташламалы йөрү хокукына ия булган пассажирлар файдалану өчен каралган. Система операторы, вәкаләтле оешмалар тарафыннан шәхси мәгълүматлар базасын тиешле формада тәкъдим иткәндә, БСК нигезендә шәхсиләштерелгән юл йөрү билетларын эшләп чыгара

һәм аларны тарату пунктларына тапшыра. Чыгарылыштан соң оператор АСОП мәгълүматлар базасына ПБ турында мәгълүмат язуны башкара. Оператор БСК нигезендә шәхсиләштерелгән ПБ чыгаруга чыгым тотмый.

Шәхсиләштерелгән транспорт карталарын, банк кушымтасы белән, оператор тиешле банк белән үзара хезмәттәшлек итеп эшләп чыгара. Чыгару тәртибе карта төренә карап билгеләнә.

3.5.2 Транспорт предприятиеләре.

Транспорт предприятиеләре структурасындагы үзгәрешләр юл йөрү документларын тикшерү җайланмасыннан (УППД) мәгълүмат җыю, аларны беренчел эшкәртү һәм Система операторына тапшыру, шулай ук АСОП БДнан НСИ алу һәм башка функцияләрне үтәү белән шөгыльләнүче бүлекчәне төзүдән гыйбарәт.

АСОП эше белән бәйле транспорт предприятиеләре функцияләренә һәм техник чараларына карата таләпләр.

1. Төп функцияләр һәм АСОП операторы белән оештыру эшләре буенча хезмәттәшлек:

• транспортны үз акчалары хисабына БСК аша ПБ белән йөрү өчен автоматлаштырылган түләү чаралары белән тәэмин итү;

• пассажирлар ташу;

• автоматлаштырылган контроль чараларын кулланып, пассажирлар тарафыннан күрсәтелә торган ПБны БСКда тикшерү;

• БСКга куелган ПБ турындагы мәгълүматларны УППДдан уку;

• системасы операторының мәгълүмат үзәге белән мәгълүматлар алмашу;

• АСОП операторыннан пассажирлар, шул исәптән ташламалы пассажирлар ташыган өчен түләүләр алу.

2. Транспорт чаралары бортында ПБ контроле: ПБны тикшерү өчен УППД экранына ПБның гамәлдә булу вакыты һәм калган сәфәр саны турында мәгълүматлар чыгарылырга тиеш.

УППДда түбәндәге мәгълүматны автоматик рәвештә тикшерү үткәрелергә тиеш:

•ПБда аның «кара исемлек” тә булуы турында билге булу;

• йөрү билетының гамәлдә булу срогы;

• түләнгән сәфәрләр булу (әгәр бу ПБ сәфәр санына яки тариф берәмлекләре саны буенча булган очракта);

• транспортның әлеге төрендә йөрү билетын куллану мөмкинлеге;

• әлеге территориядә йөрү билетын куллану мөмкинлеге (билет башка АСОП территориясендә бирелгән очракта);

• Шәһәр яны маршрутларында файдаланганда пассажирның сәфәренең юл ераклыгы турында мәгълүматлар.

УППД шулай ук әлеге маршрутның агымдагы рейсында картаны кабат күрсәтү фактын да тикшерергә тиеш. Моннан тыш, җайланмага кетелгән картаның АСОПның «кара исемлегендә» булмавы тикшерелергә тиеш

3. ПБ контроле вакытында алынган мәгълүматны беренчел эшкәртү.

Смена тәмамлангач, кондуктор УППДны паркка тапшырырга һәм синхронлаштырырга тиеш.

3.5.3. БСК нигезендә ПБ сату буенча агент оешмалар.

БСК нигезендә ПБ ресурсын сату һәм тулыландыру БСКның мәгълүматлар язмасында, шулай ук АСОП мәгълүмат базасында булырга тиеш. Бу операция төрле сату җайланмалары белән башкарылырга тиеш: кассир АРМы, АППБ, түләү терминалы, мобиль терминал, NFC ярдәмендә кәрәзле телефон.

БСК нигезендә ПБ сату берничә этапта башкарылырга тиеш:

• хәзерге вакытта БСКга язылган ПБ турында мәгълүмат алу (әгәр БСК заготовка булмаса);

• АСОПның БДнан әлеге БСКка, тарифлар таблицасына язылырга мөмкин булган ПБ төрләре турында мәгълүмат алу.

Пассажирдан яңа ПБ өчен түләү алу яки гамәлдәгеләрен тулыландыру һәм БСКга һәм АСОПның БДна тиешле мәгълүматны язу. Башкарылучы функцияләр:

• БСК да барлык төр ПБ ны сату һәм тулыландыру;

• яңартылган БСК һәм алдан әзерләнгән БСКларны сату;

• кәрәзле элемтә каналлары аша түләүле ПБ уздыру.

3.5.4. БСК нигезендә шәхсиләштерелгән ташламалы ПБ заказчысы.

Шәхсиләштерелгән ташламалы ПБ заказчысының бурычы ташламалы категорияләрдәге гражданнарның мәгълүматлар базаларын махсуслаштырылган форматта әзерләүдә, шулай ук АСОП тарафыннан формалаштырыла торган статистик хисапларны эшкәртү һәм кирәк булган очракта белешмәләрне төзәтүдән тора.

Башкарыла торган функцияләре.

БСКда шәхсиләштерелгән ПБ чыгару түбәндәге этаплардан тора:

• социаль яклау органнары белешмәләре нигезендә ташламалы категория гражданнары регистрын формалаштыру;

• БСКда ташламалы ПБ чыгару өчен анкеталар һәм документлар кабул итү;

• пассажирны фотога төшерү, яисә ташламалар бирә торган оешмалардан алынган әзер фотографияләрне куллану;

• мәгълүматлар базасын формалаштыру һәм аны БСКда ташламалы ПБ чыгару өчен операторга тапшыру;

• система операторына БСКда ташламалы ПБ әзерләгән өчен акча күчерү;

• система операторыннан ташламалы БСК алу һәм аларны гражданнарга бирү.

3.6. БСК нигезендә ПБ ярдәмендә йөрүне тикшереп торуга куела торган таләпләр.

Юл йөрү документларын тикшерү җайланмасы (УППД) юл йөрү билетларының чынлыгын автоматлаштырылган рәвештә тикшерү һәм пассажирлар йөрүнең ераклыгын исәпкә алу өчен билгеләнергә тиеш.

УППД җайланманы яки кондукторлар, яки кондукторлар эшен тикшерүче ревизорлар кулланырга мөмкинлек бирә торган программа белән тәэмин итүнең ике варианты белән кулланылырга тиеш.

Тикшерү вакытында пассажир билеты УППДга куела, шуннан соң түбәндәге параметрларны тикшерү узарга тиеш:

• йөрү билетының “кара исемлектә” булу- булмавы;

• йөрү билетының гамәлдә булу срогы;

• түләнгән сәфәрләр булу (әгәр бу ПБ сәфәр санына яки тариф берәмлекләре саны буенча булса);

• йөрү билетын транспортның әлеге төрендә куллану мөмкинлеге;

• йөрү билетын әлеге территориядә куллану мөмкинлеге.

• Тикшерү уңышлы узган очракта, билеттан бер тапкыр йөрү яисә билгеле бер санда тариф берәмлекләре киметелергә тиеш (ПБ сәфәр санына яисә тариф берәмлекләре санына булса), картага маршрут, рейс номеры һәм йөрү билетын күрсәтү вакыты турында язылырга һәм әлеге ПБны тикшерү турында җайланма хәтеренә язылырга тиеш, шуннан соң йөрү түләнгән дип санала.

Рейс яки эш сменасы тәмамлангач, предприятиенең барлык УППД хәтеренә язылган ПБ турында барлык мәгълүматлар бердәм АСОП БДга юлланырга тиеш.

3.7. АСОП мәгълүматлар базасында куела торган таләпләр.

АСОП мәгълүматлар базасы системаның транспорт предприятиеләренең УППДдан һәм сату җайланмаларыннан кергән, БСКда булган барлык ПБларның агымдагы торышы турында оператив мәгълүматны үз эченә алган, шулай ук АСОП эше эчен кирәкле башка гомуми системалы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат үзәге булып тора.

Мәгълүматларны эшкәртү һәм идарә итү БД серверы чаралары белән башкарылырга тиеш.

Стационар һәм мобиль түләү терминалларын программа белән тәэмин итү буенча мәгълүматлар алмашу тиешле кушымталар серверларын кулланып башкарылырга тиеш.

Махсуслаштырылган бурычларны хәл итү өчен аерым ярдәмче системалар каралган:

• ташламалы пассажирларның мәгълүматлар базасын алып бару ярдәмче системасы (ПВБДЛП);

• юл йөрү билетларының мәгълүматлар базасын алып бару ярдәмче системасы (БДПБ);

• системаның торышын мониторинглау ярдәмче системасы (МСС);

• норматив-белешмә мәгълүмат белән идарә итү һәм хисапларны формалаштыру системасы (ИФО).

АСОП БДда саклана торган мәгълүматны актуальләштерү максатларында, билгеләнгән вакыт периодлыгында белән түбәндәге операцияләр башкарылырга тиеш:

• ПБ белән булган операцияләр тарихын архивлаштыру яки чистарту;

• ташламалы пассажирларның мәгълүматының үзгәреш тарихын архивлаштыру һәм чистарту;

• вакыйгалар тарихын һәм җиһазлар торышын чистарту;

• билгеле бер чорларда файдаланылган сәфәр санын чистарту;

• гамәлдәге ПБ инвентаризациясен исәпләү, алдагы инвентаризация мәгълүматлары сакланган очракта, файдаланылмаган сәфәрләр саны күрсәтеп, гамәлдәге ПБларның исемлеген төзүне һәм саклауны күздә тота (сәфәр саны буенча булган ПБлар өчен); яраклылык вакыты чыккан ПБдагы сәфәрләрнең гомуми ресурсын инвентаризацияләүне исәпләү;

• мәгълүматлар базасын архивлаштыру;

• ПБ номеры, датасы һәм контроль вакыты.

Операциянең нәтиҗәсе (күрсәтү, сәфәрне исәптән чыгару, нульле йөрү ресурсы, ПБ вакыты чыккан) ПБ турында мәгълүматларны эшкәрткәндә БДда булган ПБ турындагы мәгълүматлар белән чагыштыру башкарылырга тиеш, шуннан соң БДта түбәндәге мәгълүматлар теркәлә:

• “кара исемлектә” тора һ.б.;

• УППД номеры, маршрут номеры һәм рейс номеры;

• тикшерүдән соң ПБда калган ресурс.

3.8. Акчасыз исәп-хисап буенча йөрү өчен түләүгә куела торган таләпләр

АСОП пассажирлар тарафыннан акчасыз исәп-хисап буенча юл йөрү өчен түләүне кабул итәргә тиеш. Акчасыз исәп-хисап буенча түләүләр системасы түбәндәге мөмкинлекләр бирергә тиеш:

• үз хезмәткәрләренә ташламалы йөрү хокукын бирә торган оешмалардан система операторының исәп-хисап счетына күчерелгән акчаларны пассажирлар карталары номерлары буенча бүлү турында мәгълүматларны кабул итәргә;

• акчасыз исәп-хисап буенча түләүләрне түләү Интернет-системасы аша БСКны тулыландыру өчен кулланырга;

• юл билетына акча салганда карта белән бәйле булган акчасыз сумманы кассирның АРМда кулланырга;

• юл йөрү өчен түләүнең акчалата һәм акчасыз исәп-хисапның суммасын аерым исәпкә алырга;

• акчасыз исәп-хисап буенча операцияләр буенча хисап формалаштыру.